РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ВАРЯШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XL УТЫРЫШЫ**

**КАРАР**

14 март 2024 ел № 69

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 28.11. 2018 ел 1 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексына туры китерү максатыннан, прокурорның 22.01.2024 № 02-08-01-2024 протестын үтәү максатыннан, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 28.11.2018 ел 1 нче карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 .2 пунктның 1 пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир участогы өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы өчен сатып алынган (бирелгән) җир участокларыннан тыш эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше)»;

1.2. 1 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

1.3. 2 пунктның 4 пунктчасында «торак пунктлар җирләре өлешендә» дигән сүзләрне»торак пунктлар җирләре составында» дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.4. 5 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Салым түләү җир кишәрлекләре булган урында башкарыла».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы `хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар РФ Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы З.З.Галиева